АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 09.08.2024 1216 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы башкарма комитетының «Торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 18 февралендәге 155 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 18 февралендәге 155 номерлы карары белән расланган, торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 3.3.2.1. пунктындагы 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәне формат һәм логик яктан тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә бердәм портал тарафыннан автоматлаштырып, мөрәҗәгать итүченең гарызнамәнең электрон формасындагы һәрбер юлын тутыру процессында башкарыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон рәвештә тутырылган кырының корректлы булмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры гарызнамәнең электрон формасында ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр ителә».

1.2. Регламентның 2.6.1. пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) социаль түләүләрне алу турында белешмәләр - Россия Федерациясенең пенсия һәм социаль иминләштерү фонды;».

1.3. Регламентның 2.6.1. пунктындагы 15 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15) индивидуаль шәхси счет иминият номеры турында белешмәләр (СНИЛС) - Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фонды;».

1.4. Регламентның 2.6.1. пунктындагы 17 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) гариза законлы вәкил тарафыннан бирелгән очракта мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ (Россия Федерациясе гражданлык хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан бирелгән документ) - Россия Федераль салым хезмәте, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды;»

1.5. Регламентның 2.6.1. пунктындагы 18 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18) фамилия-исем төркеменең, туу датасының, җенесенең һәм мәҗбүри пенсия иминияте системасындагы аерым шәхси счетның иминият номерының туры килүен тикшерү – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының;».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева